"Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Иске Барыш авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Советы КАРАРЫ

2016 елның 3 октябре № 30

**Гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Иске Барыш авыл җирлеге территориясендә җирле референдумны билгеләү турында**

"Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында" 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, "Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, "Җирле референдум турында" 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Иске Барыш авыл җирлеге Уставының 15 статьясы, "Җирле референдум үткәрү инициативасы турында", Иске Барыш авыл җирлеге башлыгының 2016 елның 26 сентябрендәге 8 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Иске Барыш авыл җирлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Иске Барый авыл җирлеге территориясендә гражданнарга үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум 2016 елның 20 ноябренә билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган сорауларны:

«2017 елда үзара салым кертүгә сез 18 яшькә җиткән һәр гражданнан - 500 (биш йөз) сум, җирлек территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр гражданнан, ташламалы категориядән тыш (беренче төркем инвалидлары, Бөек Ватан сугышында катнашучылар, күп балалы гаиләләрдә биш һәм аннан да күбрәк балигъ булмаган балалары, көндезге формада белем алучы студентлар) суммасында килешәсезме?

Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

*** - җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:**

- вак ташлы өслекле юлны ремонтлау: Иске Барыш авылы, Чишмә ур., Мәктәп ур., у. Елга урамы; Кыртапа авылы, Чишмә ур., Тынычлык ур., Яшьләр ур., Мәктәп ур.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының сайтында урнаштырырга һәм муниципаль берәмлек территориясендә түбәндәге адреслар буенча махсус мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә:

- -Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Иске Барыш авылы, Үзәк ур., 15.
- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Кыртапа авылы, Мәктәп ур., 10 йорт.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Иске Барыш авыл җирлеге башлыгы И.Р. Җиһаншинга йөкләргә

Татарстан Республикасы Кама Тамагы

муниципаль районының Иске Барыш

авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Советы рәисе,

Иске Барыш авыл җирлеге башлыгы И.Р. Җиһаншин